**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительный комитет Азнакаевского муниципаль районы**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

Ленин ур., 22 й., Азнакай ш., 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**"14" июль 2022 ел** **№ 188**

Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү турында

2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем шартнамәләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законы белән, һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм күрсәтелгән законга кушымтада бәян ителгән салым салынырга тиешле мөлкәт хакының чик күрсәткечләрен билгеләү методикасы, Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 13 маендагы 142 номерлы «Азнакай муниципаль районы буенча 2022 елның II кварталына гомуми торак мәйданының бер квадрат метры бәясенең нормативын билгеләү турында» карары белән, шулай ук Россия Федерациясе Торак кодексының 49, 51 статьяларына таянып, карар бирә

1. Гражданнарны аз керемле дип тану турында карар кабул итү өчен түбәндәге чик күрсәткечләрне билгеләргә:

1.1. Гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт хакы ставкасы:

1.1.1. Ялгыз яшәүче граждан өчен - 561 204 сум;

1.1.2. Ике кешелек гаилә өчен - 1 122 408 сум;

1.1.3. Өч кешелек гаилә өчен - 1 683 612 сум;

1.1.4. Дүрт кешелек гаилә өчен - 2 244 816 сум;

1.1.5. Биш кешелек гаилә өчен - 2 806 020 сум;

1.1.6. Алты кешелек гаилә өчен - 3 367 224 сум;

1.1.7. Җиде кешелек гаилә өчен - 3 928 428 сум;

1.1.8. Сигез кешелек гаилә өчен - 4 489 632 сум;

1.1.9. Тугыз кешелек гаилә өчен - 5 050 836 сум;

1.1.10 Ун кешелек гаилә өчен - 5 612 040 сум.

1.2. Гаиләнең бер әгъзасына туры килә торган айлык уртача җыелма керемнең кимчелекле күрсәткече 15 162 сум 35 тиен тәшкил итә.

2. Азнакай муниципаль районы башкарма комитетының 2022 елның 16 маендагы 143 номерлы «Һәр гаилә әгъзасына яисә ялгыз яшәүче гражданга туры килә торган керемнең чик күрсәткечләрен һәм гаилә әгъзалары яисә ялгыз яшәүче граждан милкендәге мөлкәтнең хакын билгеләү турында» карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aznakayevo.tatar.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов